| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 Баулы шәһәре №232

Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 16 октябрендәге 222 номерлы “Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында” карарына өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 4 августындагы 416-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм һәм Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының үтәлеш үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль законнарына ярашлы, Баулы муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 16 октябрендәге 222 номерлы “Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында” (2020 елның 29 маендагы 262 номерлы, 2021 елның 14 декабрендәге 91 номерлы, 2022 елның 11 апрелендәге 110 номерлы, 2022 елның 18 августындагы 126 номерлы, 2023 елның 2 февралендәге №162, 2023 елның 20 июнендәге 191 номерлы, 2023 елның 26

октябрендәге 222 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

21 статьяның 3 пункты һәм 22 статьяның 3 пункты гамәлләрен 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатырга;

2 пунктта 25 статьяда:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме, Җирлекнең Башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә, бюджет чыгымнарының максатчан статьясы буенча, һәр программа буенча бюджет турында карар белән раслана.»;

икенче абзацта «вакытында расланырга тиеш» сүзләрн «билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта расланырга тиеш» сүзләре белән алмаштырырга;

өченче абзацта «үз көченә кергән көннән алып ике ай» сүзләрен «агымдагы финанс елының 1 апреле.» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат Рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

Баулы муниципаль районы Башлыгы
Район Советы рәисе И.И. Гозәеров